ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№6 Акбаш ав. «27»май 2021 ел

Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 1 апрелендагы 7 санлы «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы түләттерү буенча өстәмә нигезләр турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсе, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393 санлы боерыгының 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның апрелендагы 7 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 бүлектә:

Икенче абзацта «бурыч барлыкка килү датасы өч елдан артык булганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Үлгәннән соң 6 ай дәвамында мирас хокукын белдермәгән очракта, җир салымы һәм үлгән физик затлар милкенә салым буенча» дигән өченче абзацны төшереп калдырырга;

Дүртенче Абзац «-җир салымы һәм физик затлар милкенә салым буенча бурычларны өч елдан артык түләттерүгә ышанычсызлык барлыкка килү көне белән киләсе елның һәр 1 числосына» дигән сүзләрне түбәндәге текстка алмаштырырга: «физик затлар мөлкәтенә җир салымы һәм милеккә салым, пенялар һәм әлеге салымнар буенча бурычлар барлыкка килү вакыты 3 елдан артык булган очракта»;

Түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« -башкарма производство турында 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы Федераль законның 46, 47 маддәсенең 1 өлешенең 3, 4 бүлекләрендә билгеләнгән очракларда башкарма документны түләтүчегә кире кайтару турында суд приставы тарафыннан карар чыгарганда җирле салымнар,пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча».

2. Әлеге карар үз гамәлен бурыч барлыкка килгән мизгелдән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

3.Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синагатуллина